ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРЖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерже шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» февраль 2020 ел № 72

««Форпост» җәмәгать тәртибен
саклау буенча иҗтимагый берләшмәләр үзәге»
муниципаль бюджет учреждениесе атамасын
««Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча
яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге»
муниципаль бюджет учреждениесе дип үзгәртү турында

Россия Федерациясе Граждан кодексының 54 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Коммерциясез оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 9.2, 14, 24 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында яшьләр һәм дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 03.11.2012 № 1986-р боерыгына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 18 июнендәге 1451-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте өлкәсендә эшчәнлек башкаручы учреждениеләр өчен типик нигезләмәләрне раслау турында» 2009 елның 14 сентябрендәге 317 номерлы боерыгы нигезендә, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасының дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясен раслау турында» 2016 елның 4 февралендәге 63 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы уставыныц 46 статьясына таянып. Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы ««Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча иҗтимагый берләшмәләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе атамасын ««Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе дип үзгәртергә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы ««Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең Уставын расларга (кушымта итеп бирелә).

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы ««Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча иҗтимагый берләшмәләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе директорын гамәлдәге законнар нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы ««Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча иҗтимагый берләшмәләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе Уставын теркәү өчен документлар тапшырганда салым органнарында мөрәҗәгать итүче булып чыгыш ясарга вәкаләтле итеп билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы ««Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча иҗтимагый берләшмәләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе Уставынын яңа редакциясен, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районынын ««Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе Уставын дәүләт теркәвенә алганнан бирле, раслау турында» 2018 елның 23 августындагы 377 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында http://agryz.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты житәкчесенең беренче урынбасары Р. Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет житәкчесе** **А.С. Авдеев**